## Уважаемый читатель!

Сборник документов и правовых актов муниципального образования города Казани публикует решения городских властей и выходит еженедельно, по четвергам. Перечень документов, вошедших в новый Сборник, анонсируется по понедельникам на портале kzn.ru в разделе новостей.

Найти нужный вам выпуск можно в любой городской библиотеке Казани, в том числе и детской.

Приобрести свежий номер Сборника, а также вышедший на предыдущей неделе вы можете в киосках «Горпечати».

Если у вас нет необходимости покупать печатную версию, то на сайте kzn.ru в рубрике «Документы» ведется электронный архив.

Выписать журнал можно в любом почтовом отделении. Подписной индекс 16293.

Служба альтернативной подписки и курьерской доставки ООО «Урал-Пресс Казань» оформит для вас подписку по телефону 277-95-57.

Все вопросы, касающиеся Сборника, присылайте по адресу sbornik_kgoc@mail.ru или задавайте по телефону 8-903-313-42-26.

---

## Хөрмәтле укучы!

Атна саен пәнҗешәмбе көннәрендә дөнья күргән Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актлар һәм документлар җыентыгында шәһәр хакимиятенең яңа карарлары бастырыла. Яңа Җыентыкка кергән документлар исемлегенә һәр дүшәмбе kzn.ru порталының яңалыклар бүлегендә анонс ясала.

Басманың сезгә кирәкле санын Казанның теләсә кайсы шәһәр, шул исәптән балалар китапханәсендә дә табарга була.

Җыентыкның өр-яңа һәм шулай ук узган атнада чыккан санын сатып алу өчен «Горпечать» киоскларына мөрәҗәгать итә аласыз.

Әгәр сезнең басма версияне сатып алу ихтыяҗы булмаса, kzn.ru сайтының «Документлар» рубрикасында урнаштырылган җыентыкларның электрон архивына мөрәҗәгать итә аласыз. Монда пәнҗешәмбе көннәрендә өр-яңа саннар да урнаштырыла.

Журналга теләсә кайсы почта бүлегендә язылырга мөмкин. Язылу индексы 16293.

«Урал-Пресс Казань» ҖЧҖ альтернатив язылу һәм китереп бирү хезмәте сезне 277-95-57 телефон номеры аша яздырыр.

Җыентыкка кагылган барлык сораулар белән sbornik_kgoc@mail.ru электрон адресы яисә 8-903-313-42-26 телефоны аша мөрәҗәгать итә аласыз.

## СОДЕРЖАНИЕ

**Постановление Исполнительного комитета г. Казани от 27.12.2013 г. №11947**
Об изменении организации дорожного движения по ул.Вишневского 3

## ЭЧТӘЛЕК

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 27 декабреннән 11947-нче номерлы карары**
Вишневский урамы буенча юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртү турында 5

# Постановление Исполнительного комитета г. Казани

от 27.12.2013 г. №11947

## Об изменении организации дорожного движения по ул.Вишневского

Руководствуясь Федеральным законом от 10.12.1995 №196-ФЗ «О безопасности дорожного движения», Федеральным законом от 06.10.2003 №131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Федеральным законом от 08.11.2007 №257-ФЗ «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности в Российской Федерации» и Законом Республики Татарстан от 03.08.2009 №43-ЗРТ «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности в Республике Татарстан», в целях увеличения пропускной способности ул.Вишневского:

1. **Постановляю**:

1.1. ввести запрет на осуществление левого поворота транспортным средствам, за исключением маршрутных транспортных средств городского пассажирского транспорта, по ул.Вишневского, на пересечениях с ул.Достоевского и ул.Амирхана Еники;

1.2. Финансовому управлению Исполнительного комитета г.Казани (А.Д.Гарипов) выделить Комитету по транспорту Исполнительного комитета г.Казани средства в сумме 296,908 тыс.рублей для Муниципального бюджетного учреждения «Автоматизированная система управления дорожным движением» г.Казани на увеличение муниципального задания по установке и содержанию дорожных знаков, светофорных объектов в 2013 году за счет остатка средств бюджета г.Казани по состоянию на 01.01.2013;

1.3. Комитету по транспорту Исполнительного комитета г.Казани (А.К.Абдулхаков) обеспечить целевое использование выделенных средств;

1.4. комитету экономического развития Аппарата Исполнительного комитета г.Казани (И.С.Шакиров) включить в Программу капитальных расходов г.Казани на 2013 год расходы на установку дорожных знаков в сумме 296,908 тыс.рублей за счет средств бюджета г.Казани;

1.5. опубликовать настоящее постановление в Сборнике документов и правовых актов муниципального образования города Казани и разместить его на официальном сайте г.Казани.

2. **Рекомендую**:

2.1. Отделу Государственной инспекции безопасности дорожного движения Управления Министерства внутренних дел Российской Федерации по городу Казани (Р.А.Ибрагимов) обеспечить контроль за соблюдением Правил дорожного движения по ул.Вишневского и прилегающим улицам;

2.2. отделу по связям с общественностью и средствами массовой информации аппарата Казанской городской Думы (С.Ю.Лобов) оповестить через средст-

ва массовой информации о введении запрета на осуществление левого поворота по ул.Вишневского, на пересечениях с ул.Достоевского и ул.Амирхана Еники.

3. **Возлагаю** контроль за исполнением настоящего постановления на первого заместителя Руководителя Исполнительного комитета г.Казани Р.К.Нигматуллина.

**Руководитель А.В.Песошин**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының

2013 елның 27 декабреннән 11947-нче номерлы карары

# Вишневский урамы буенча юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртү турында

1995 елның 10 декабреннән 196-ФЗ номерлы «Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы турында»гы Федераль закон, 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, 2007 елның 8 ноябреннән 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Федераль закон һәм Татарстан Республикасының 2009 елның 3 августыннан 43-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Законы белән эш итеп, Вишневский урамы буенча юл үткәрүчәнлеген арттыру максатыннан:

1. **Карар бирәм:**

1.1. Вишневский урамы буенча, Достоевский урамы белән Әмирхан Еники урамнары киселешендә шәһәр пассажирлар транспортының маршрут транспорт чараларыннан тыш, транспорт чараларына сул якка борылуны тыярга;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә (А.Д.Гарипов) Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына Казан шәһәренең «Юл хәрәкәте белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы» муниципаль бюджет учреждениесе өчен 2013 елның 1 гыйнварына Казан шәһәре бюджетының калган өлеше хисабына 296, 908 мең сум күләмендәге акчаны 2013 елда светофор объектларын, юл билгеләрен урнаштыру һәм карап тоту буенча муниципаль биремне арттыруга бүлеп бирергә.

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.К.Габделхаков) бүленгән акчаны максатлы файдалануны тәэмин итәргә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының аппаратының Икътисади үсеш комитетына (И.С.Шакиров) Казанның 2013 елга Капиталь чыгымнар программасына Казан шәһәре бюджеты хисабына 296, 908 мең сум күләмендә юл билгеләре кую чыгымнарын кертергә.

1.5. әлеге карарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актлар һәм документлар җыентыгында бастырып чыгарырга һәм Казан шәһәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

2. **Киңәш итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә (Р.Ә.Ибраһимов) Вишневский һәм якындагы урамнар буенча Юл кагыйдәләре үтәлешен контрольгә алуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә (С.Ю.Лобов) массакүләм мәгълүмат

чаралары аша Вишневский урамы буенча, Достоевский һәм Әмирхан Еники урамнары киселешендә сул якка борылышның тыелуы турында җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга **йөклим**.

**Җитәкче А.В.Песошин**

# ДЛЯ ЗАМЕТОК/ ИСКӘРМӘЛӘР ӨЧЕН

**Сборник документов и правовых актов муниципального образования города Казани.**
**Учредитель и издатель:**
МАУ «Казанский городской общественный центр».
420014, РТ, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 3.
**Адрес редакции:** 420014, РТ, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 3, каб. №642.
**Телефон:** 8-9033134226.
**E-mail:** sbornik_kgoc@mail.ru.
Цена – свободная. Подписной индекс – 16293.
**Главный редактор: Шакирзянова Г.Р.**
**Перевод на татарский язык: Ситдыкова А.Ф.**
**Дизайн и верстка: Каурова Ю.В.**
**Оформление и корректура:**
редакция Сборника документов и правовых актов
муниципального образования города Казани.
Издание зарегистрировано в Управлении Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Республике Татарстан (Татарстан).
Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 16-00919 от 05.12.2012.
Печать офсетная.
Объем 8 страниц. Тираж 300 экз.
Отпечатано ИП Гариповой Г.Г.
420138 г. Казань, пр. Победы, д. 30
Подписано в печать: 28.12.2013 г.

---

**Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актлар һәм документлар җыентыгы.**
**Оештыручы һәм бастыручы:**
«Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» МАУ.
420014, ТР, Казан шәһ., Кремль ур., 3 йорт.
**Редакциянең адресы:**
420014, ТР, Казан шәһ., Кремль ур., 3 йорт, 642-нче номерлы кабинет.
**Телефон:** 8-9033134226.
**E-mail:** sbornik_kgoc@mail.ru.
Бәясе – ирекле. Язылу индексы – 16293.
**Баш редактор: Шакирҗанова Г.Р.**
**Татарчага тәрҗемә итүче: Ситдыкова А.Ф.**
**Дизайн һәм верстка: Каурова Ю.В.**
**Дизайн һәм корректура:**
Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актлар һәм документлар җыентыгы редакциясе.
Басма Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсендә теркәлгән.
Басманы теркәү турында 2012 елның 5 декабреннән ТУ 16-00919 номерлы таныклык.
Офсет басма.
Күләме 8 бит. Тираж 300 данә.
Гарипова Г.Г. шәхси эшмәкәр тарафыннан бастырылды
420138 Казан шәһ., Җиңү проспекты, 30 йорт.
Басмага 2013 елның 28 декабрь көнендә кул куелды.